ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «11» сентября 2019 № 716

**2014 елның 24 ноябрендәге 1243 номерлы “2015-2021 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру” карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы тору системасын камилләштерү максатларында һәм “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге “2015-2021 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру” дәүләт программасын раслау турында” 512 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 17 июнендәге 495 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. 2014 елның 24 ноябрендәге 1243 номерлы “2015-2021 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру” карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә ”2015-2021”санын “2015-2022” санына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында “2015-2021 елларга коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру” муниципаль программасында (алга таба – Программа):

исемендә ”2015-2021”санын “2015-2022” санына алмаштырырга;

Программаның паспортында:

“программаның исеме” юлында ”2015-2021”санын “2015-2022” санына алмаштырырга;

“программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары” юлында ”2015-2021”санын “2015-2022” санына алмаштырырга;

“Программаның үтәлеше еллап бүленгән финанслау чыганаклары һәм күләмнәре” юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Ел | ТР Арча муниципаль районының җирле бюджеты акчалары |
|---|---|
| 2015 | 35,0 |
| 2016 | 40,0 |
| 2017 | 50,0 |

| | |
|---|---|
| 2018 | 65,0 |
| 2019 | 75,0 |
| 2020 | 80,0 |
| 2021 | 80,0 |
| 2022 | 80,0 |
| Барлыгы | 505,0 |

Моннан тыш, Программа чараларын тормышка ашыруда чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчаларны файдалану күздә тотыла»;

«2015-2021 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслауны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.Галимуллин

Кушымта

# “2015-2022 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру” муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программаны чаралары буенча финанслау

| Төп чараларның аталышы | Башкаручылар | Төп чараларны башкару срогы | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы, үлчәү берәмлеге | Индикаторлар күрсәткече | | | | | | | | | Финанслау (Арча муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән), мең сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |
| **Максат :коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү, аңа этәрә торган сәбәпләргә каршы тору, җәмгыятьтә коррупциягә каршы түзеп тора алмаучылыкны булдыру** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| **1 нче бурыч. Коррупциягә каршы тору коралларын һәм механизмнарын камилләштерү, шул исәптән хокукый һәм оештыру ягыннан** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. Федераль законнарны үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасында гамәлдәге коррупциягә каршы нормаларны куллану практикасын гомумиләштерү нигезендә Татарстан Республикасының коррупциягә каршы көрәш турында законнары һәм башка норматив хокукый актларына, муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү һәм норматив хокукый актлар эшләү | Арча МР Советы, Арча МР Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының кадрлар сәясәтенә эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизмга керткән өлеше, процентларда | 94 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2. Коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җирле үзидарә органнары бүлекчәләренең (Россия Федерациясе Президентынын 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 номерлы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге 711-ПУ номерлы указлары нигезендә) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затларының) нәтиҗәле | Коррупция чел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| эшләве, югарыда күрсәтелгән функцияләрне гамәлгә ашыручы кадрларның тотрыклылыгы принцибын үтәү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2.1. Муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы тору турындагы законнар таләпләрен үтәп, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан бирелә торган хезмәткәрләрнең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү. Тикшерү барышында ачыкланган хокук бозулар турында ТР прокуратурасы органнарына хәбәр итү | Коррупция чел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2.2. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт турындагы законнарда каралган чикләүләрне һәм тыюларны, шул исәптән Федераль салым хезмәтенең «Юридик затларның бердәм дәүләт реестры» һәм «Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры» мәгълүматлары базаларыннан файдаланып, эшкуарлык эшчәнлегендә катнашу предметына тикшерү үткәрү (елга кимендә бер тапкыр) | Коррупция чел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2.3. Законда билгеләнгән тәртиптә эшкә алучының вәкиле белән эшкә керә торган муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр каршылыгы булу яки барлыкка килү мөмкинлеге турындагы мәгълүматны тикшерү | Коррупция чел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләре | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | нең вазыйфаи затлары | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2.4. Эшкә алучының (эш бирүче) вәкиле тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турындагы мәгълүматларны тикшерү | Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2.5. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан функцияләр тормышка ашырганда барлыкка килә торган коррупция куркынычы тууны бәяләүне системалы рәвештә үткәрү һәм коррупция куркынычы туу белән бәйле булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә төгәллекләр кертү | Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары | ел саен | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2.6. Керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында тиешле исемлеккә кертелгән затлар һәм күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәте (шул исәптән чит илләрдә), транспорт чаралары, счетлар, кредитлар, кыйммәтле кәгазьләр турында мәгълүмат базаларыннан файдаланып тапшырыла торган белешмәләргә, хезмәт килешүе шартларында әлеге оешма белән идарә итү (административ) муниципаль хезмәткәр вазыйфаларына керсә, гражданлык-хокукый килешүе шартларында | Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары | кертү – 2015 ел, куллану- 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| вазыйфа биләүгә (гражданлык-хокукый шартнамәләр) ризалык бирү турында гражданнар мөрәҗәгатьләрен җыю, системалаштыру һәм карау яисә әлеге оешмада эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) мониторинг һәм автоматлаштырылган анализ ясау максатында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау бүлекчәләре (коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы вазыйфаи затлар) эшчәнлегенә махсус программа нигезендә эшләнгән компьютер программалары кертү һәм куллану | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2.7. Муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның шәхси эшләрен алып баруга кагылышлы өлешендә, мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау максатларында, кадрлар эшен гамәлгә ашыру, шул исәптән күрсәтелгән вазыйфаларга билгеләгәндә һәм мондый хезмәткә кергәндә бирелә торган анкеталарда булган аларның туганнары һәм милекчеләре турында (үз абыйлары һәм сеңелләренең ире яисә хатыны, үз иренең яки хатынының абыйлары һәм апалары) белешмәләрне актуальләштерү | Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары | 2018 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.3. Арча муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен житәкләү буенча Комиссия эшчәнлегенең ачыклыгын, шул исәптән аларның эшчәнлегенә җәмәгать советлары һәм гражданлык җәмгыятенең башка институтлары вәкилләрен җәлеп итү юлы белән, тәэмин итү | Район башлыгы ярдәмчесе | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.4. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм федераль һәм республика законнарының билгеләнгән таләпләре нигезендә мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләренең нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү | Район башлыгы урынбасары | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.5. Законнар белән билгеләнгән тәртипләр нигезендә Арча муниципаль районы сайтында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат урнаштыру | Коррупция чел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затлары | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.6. Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тәэмин итүдә методик һәм гамәли ярдәм күрсәтү | Коррупция чел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | затлары. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.7. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр уставларына оештыру-боеру, административ-хуҗалык функцияләренә ия булган учреждение җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре белән хезмәт килешүләре, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу мәсьәләләрен билгеләүче нормалар өлешендә үзгәрешләр кертү буенча эш оештыру | Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр булган җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.8. Арча муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен җитәкләү буенча Комиссиянең еллык эш планын раслауны һәм алга таба үтәүне тәэмин итү | Район башлыгы ярдәмчесе | 2015 – 2022 еллар | Үткәрелгән чаралар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| **2 нче бурыч. Норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм бетерү, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен шартлар тудыруны тәэмин итү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. Норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертизаны нәтиҗәле үткәрүне оештыру, аны уздыру нәтиҗәләрен ел саен гомумиләштерү буенча гамәли чаралар күрү | Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү буенча җаваплы затлар | 2015 – 2022 еллар | Проектлар эшләү стадиясендә коррупциягә каршы экспертиза үткәрелгән закон һәм башка норматив хокукый актларның өлеше, процентларда | 95 | 96 | 96 | 97 | 97 | 98 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 2.2. Норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен кирәкле шартлар тудыру | Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый акт проектларына коррупциягә каршы | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | экспертиза үткәрү буенча җаваплы затлар | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| **3 нче бурыч. Мониторинг тикшеренүләре үткәрү юлы белән коррупциянең торышын бәяләү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.1. Арча муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә мониторинг үткәрү | Арча МР Советы, Арча МР Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары | 2015-2022 еллар | Социологик сораштырулар оештыруда дәүләт йөкләмәсен үтәүнең тулылыгы, процентларда | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 3.2. Максатчан төркемнәр арасында коррупциячел факторларга тармак тикшеренүләре һәм коррупциягә каршы гамәлгә ашырыла торган чаралар үткәрү. Коррупциягә каршы тору кысаларында саклык чаралары булдыру өчен алынган нәтиҗәләрне куллану | Арча МР Советы, Арча МР Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 3.3.Коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыруга гражданлык җәмгыяте институтларының җәлеп ителеше, коррупция темасына район массакүләм мәгълүмат чаралары материалларына мониторинг үткәрү | Арча районы Иҗтимагый советы | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| **4 нче бурыч. Коррупциягә каршы тору буенча өйрәнүләрне һәм коррупциягә каршы пропаганданы активлаштыру, коррупциягә каршы көрәшкә кадрлар, матди, мәгълүмати һәм гражданлык җәмгыятенең башка ресурсларын җәлеп итү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.1. Коррупциягә каршы тематика буенча белем бирү программаларын кертеп, муниципаль хезмәткәрләрне квалификация күтәрү курсларына җибәрү | Арча МР Советы, Арча МР Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | Квалификация күтәрүне узган дәүләт граждан (муниципаль) хезмәткәрләре өлеше, процентларда | 33 | 33 | 33 | 33 | 33 | 33 | 33 | 33 | 33 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.1.1. Вазыйфаларына коррупциягә каршы торуда катнашу керә торган муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен еллык | Район башлыгы ярдәмчесе, кадрлар хезмәтенең | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| махсуслаштырылган курсларда күтәрү | коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.1.2. Муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларны биләү өчен муниципаль хезмәткә беренче тапкыр кергән муниципаль хезмәткәрләрне коррупциягә каршы тематика буенча дисциплиналар булган белем бирү программалары буенча махсуслаштырылган укуларга җибәрү (белем бирү программасы буенча 8 академик сәгатьтән дә ким түгел) | Арча МР Советы, Арча МР Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары | 2018 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.2. Муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук коррупциягә каршы көрәштә катнашучы җәмәгатьчелек вәкилләренең һәм башка затларның квалификациясен күтәрүгә юнәлдерелгән кыска сроклы махсуслаштырылган семинарлар оештыру һәм уздыру | Район башлыгы ярдәмчесе, кадрлар хезмәтенең коррупция чел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затлары | 2015 – 2022 еллар | Үткәрелгән чаралар саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.3. Җирле үзидарә органнарында ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә коррупциягә каршы тору буенча методик мәгълүмат материалларын эшләү, тарату һәм актуальләштерү | Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр булган җирле үзидарә органнары | 2018 – 2022 еллар | Җирле үзидарә органнарын коррупциягә каршы тору эшчәнлеген камилләштерү мәсьәләләре буенча методик материаллар белән тәэмин итү | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 4.4. Коррупциягә каршы көрәштә катнашучы иҗтимагый советларны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм гражданлык җәмгыятенең башка институтларын әлеге эшкә җәлеп итеп, муниципаль хезмәткәрләрдә һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләрендә коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру буенча эшне гамәлгә ашыру | Арча МР Советы, Арча МР Башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | Коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль оешмалар өлеше | - | 30 | 35 | 40 | 45 | 50 | 50 | 50 | 50 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.4.1. Арча муниципаль районының Иҗтимагый советы утырышларында, Арча район Советы утырышында, гражданнар җыенында коррупциягә каршы тору программаларын гамәлгә ашыру турындагы хисапларны карау | Җирле үзидарә органнары | 2018-2022 еллар | | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - |
| 4.4.2. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, шул исәптән бүләкләр алуга һәм бүләк бирүгә кагылышлы чикләүләрне үтәү буенча, әлеге эшкә Арча МР иҗтимагый советларын, коррупциягә каршы көрәштә катнашучы иҗтимагый берләшмәләрне һәм гражданлык җәмгыятенең башка институтларын җәлеп итеп, аңлату һәм башка чаралар комплексын оештыру | Җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.4.3. Коррупциягә каршы | Җирле | 2015 – | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| көрәш өлкәсендә халыкара актлар нигезләмәләрен һәм ришвәт бирү яки ришвәт алу тәкъдимнәрен яки ришвәт бирү яки ришвәт алу вәгъдәләренең җинаятьчеллеге турында чит дәүләтләр тәҗрибәсен исәпкә алып, муниципаль хезмәткәрләрнең үз-үзләрен тотышы әйләнә-тирәдәгеләргә ришвәт бирүне вәгъдә итү яки тәкъдим итү яки ришвәт алырга ризалык буларак яки ришвәт бирү турында үтенеч буларак кабул ителүгә юл куймау буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексын эшләү һәм тормышка ашыру | үзидарә органнары | 2022 еллар | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4.5. Коррупциягә каршы юнәлештәге чараларга мәгълүмати ярдәм күрсәтү, коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча җәмгыятьтә агарту эшен оештыру | "ТАТМЕДИА" АҖ "Арча-информ" филиалы | 2015 – 2022 еллар | Коррупциягә каршы укуга һәм коррупциягә каршы пропагандага бер елга планлаштырылган гомуми саннан үткәрелгән чараларның өлеше, процентларда | | | | | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.6. Коррупция темасына массакүләм мәгълүмат чаралары материалларына мониторинг үткәрү | Район башлыгы ярдәмчесе | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 4.7. "Илемнең киләчәге-минем кулларда!" темасына иншалар конкурсы, "Коррупциягә "ЮК" дип әйтик! темасына туган телдә милли мәктәп укучыларының иҗади эшләре конкурсы һәм "Намуслы яшәргә кирәк! балалар рәсемнәре конкурсы, "Закон сагында, коррупциягә каршы!" темасына һөнәри белем бирү оешмалары студентлары арасында республика иҗади эшләр конкурсы үткәрү | Арча муниципаль районы башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе» МУ | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | 5,0 | 10,0 | 15,0 | 30,0 | 40,0 | 45,0 | 45,0 | 45,0 |
| 4.8. Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр өчен коррупциягә каршы темага социаль баннерлар әзерләү | Җирле үзидарә органнары | 2015-2022 еллар | Куелган баннерлар саны | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **5 нче бурыч. Дәүләт һәм муниципаль органнар эшчәнлегенең ачыклыгын, халык өчен үтемле булуын тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәсен ныгыту, коррупциягә каршы көрәштә җәмәгатьчелек активлыгын стимуллаштыру** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының (Җирле үзидарә органнары) муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламенты нигезләмәләрен үтәвен тәэмин итү | Җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | Гражданнарның муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты белән канәгать булу дәрәҗәсе, процентларда | 75 | 75 | 80 | 85 | 90 | 90 | 90 | 90 | 90 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 5.2.Административ регламенттан файдаланганда, шул исәптән хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларны сораштыру юлы белән, муниципаль хезмәт күрсәтүгә мониторинг үткәрү | Җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 5.3. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү системасын камилләштерү, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында | Җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | Яшәү урыны буенча «бер тәрәзә»принцибы буенча муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге булган гражданнар өлеше, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, процентларда; Бер хезмәт алу өчен җирле үзидарә органнарына бизнес җәмәгатьчелеге вәкилләренең уртача мөрәҗәгать итү саны | 60 | 65 | 70 | 75 | 80 | 85 | 90 | 90 | 90 | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары рәсми сайтларының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата бердәм таләпләрне раслау турында» 2013 елның 4 апрелендәге 225 номерлы карары нигезендә Арча муниципаль районы рәсми сайтының “Коррупциягә каршы тору” бүлеген тулыландыруны оештыру | Район башлыгы ярдәмчесе, коррупция чел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләре нең вазыйфаи затлары. | 2015 – 2022 еллар | ТР Министрлар Кабинетының 2013 елның номерлы карары белән билгеләнгән законнар һәм таләпләр нигезендә рәсми сайтларын мәгълүмат белән тулыландыруны тәэмин итүче җирле үзидарә органнарының өлеше, процентларда | 60 | 65 | 70 | 75 | 80 | 85 | 90 | 90 | 90 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 5.5. Җирле үзидарә органнарында гражданнарга коррупция фактлары, аның туына сәбәпче булган шартлар турында житкерергә ммөмкинчелек бирә торган «ышаныч телефоннары», «кайнар линияләр», интернет-кабул итү, башка мәгълүмат каналларының эшләвен тәэмин итү | Җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | Ачыклыкны, дәүләт һәм муниципаль органнар эшчәнлегенең халык өчен үтемле булуын тәэмин итүгә, аларның граждан җәмгыяте белән элемтәсен ныгытуга, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыруга бер елга планлаштырылган гомуми саннан үткәрелгән чараларның өлеше, процентларда | | | | | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 5.6. Массакүләм мәгълүмат чараларында һәм интернет-сайтларда коррупциянең торышы һәм коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында еллык хисапларны урнаштыру | Район башлыгы ярдәмчесе | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 5.7. Арча муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен житәкләү Комиссиясе утырышында квартал саен гомумиләштереп һәм аның нәтиҗәләрен карап тикшереп, массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган һәм гражданнардан һәм юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләрдә булган | Арча муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен житәкләү Комиссиясе | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| вазыйфаи затлар эшчәнлегендә коррупциячел күренешләр турында мәгълүматка мониторинг үткәрү эшен оештыру | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5.8. Коррупциягә каршы тору буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан күрелә торган чаралар турында массакүләм мәгълүмат чараларына җиткерү | Җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 5.9. Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләрдә коррупциягә каршы тору турында мәгълүмат тапшыруның бүтән рәвешләрен һәм махсус мәгълүмат стендларын булдыру һәм актуаль халәттә тоту | Җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | 10,0 | 10,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| **6 нчы бурыч. Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итүдә товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алганда ачыклыкны, намуслы көндәшлекне һәм гаделлекне тәэмин итү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алуны гамәлгә ашырганда коррупция дәрәҗәсен киметүгә ярдәм итә торган чараларны гамәлгә ашыру, шул исәптән сатып алуларның ачыклыгын һәм һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү буенча чаралар уздыру, шулай ук сатып алуларда катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру | Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанслар бүлеге, җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру эшчәнлегенең үтә күренмәлелеген тәэмин иткән җирле үзидарә органнары өлеше, процентларда | 75 | 80 | 85 | 90 | 95 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 6.2. Ведомство карамагындагы оешмаларның мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау, коррупциячел куркынычларны ачыклау һәм киметү максатларында, 2011 елның 18 июлендәге «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында» 223-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның | Арча муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы, Арча муниципаль районы Контроль-хисап палатасы | 2018 – 2022 еллар | Бер елга планлаштырылган гомуми саннан үткәрелгән тикшерүләрнең өлеше, процентларда | | | | | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә ясалган сатып алуларына анализ ясау | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| **7 нче бурыч. Эшкуарлыкка (бизнес-структураларга) административ басымны эзлекле рәвештә кимету** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7.1. Җирле үзидарә, хокук саклау органнарының бизнес-структураларга административ киртәләр кую һәм тискәре йогынты ясау мәсьәләләрен карау буенча эшкуарлар белән киңәшмәләр үткәрү, шулай ук эшкуарлар арасында сораштырулар уздыру (кирәк булганда) | Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 2015 – 2022 еллар | Утырышлар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| **8 нче бурыч. Хокук саклау органнары белән хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген арттыру** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8.1. Түбәндәге мәсьәләләр буенча хокук саклау органнары белән килешү буенча мәгълүмати хезмәттәшлек:<br>- өстенлекле илкүләм проектларны һәм республика программаларын тормышка ашырганда коррупциячел хокук бозуларны ачыклау буенча законнар үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыру;<br>- районның җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең законда каралган тыюлар һәм чикләүләрне үтәү тәртибенә тикшерүләр үткәрү.<br>Тикшерү нәтиҗәләрен халыкка игълан итү;<br>- субъектларның эшмәкәрлек эшчәнлеге, торак-коммуналь хуҗалык, бюджет акчалары, дәүләт һәм муниципаль милек белән эш итү буенча коррупция фактларын ачыклау һәм ачу;<br>- ачыкланган җинаятьләрнең категорияләре буенча, коррупция булган тармаклар, | Арча районы прокуратурасы, Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге | 2015 – 2022 еллар | Дәүләт программасында каралган контроль тикшерүләрне гамәлгә ашыруның тулылыгы, процентларда | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| җинаять җаваплылыгына җәлеп ителгән вазыйфаи затлар структурасы буенча аналитик материаллар нәтиҗәләре;<br>- район халкына массакүләм мәгълүмат чаралары аша коррупционерларны фаш итү, вазыйфаи затларны биләгән вазыйфаларыннан азат итү, гаеплеләрне җаваплылыкка тарту фактлары турында хәбәр итү;<br>- бюджет акчаларын тотканда законнарны һичшиксез үтәүгә юнәлдерелгән муниципаль контроль органнары белән хезмәттәшлек | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| **9 нчы бурыч. Көнкүреш коррупциясен кимету чараларын көчәйтү** | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9.1. Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларның ата-аналарын белем бирү оешмаларында законсыз акча җыю очракларында кылынырга тиешле гамәлләр турында белешмәлекләр белән тәэмин итү | Арча муниципаль районы башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МУ | 2015 – 2022 еллар | Мәгариф оешмаларында законсыз акча җыю очракларында гамәлләр турында белешмәлек алган мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларның ата-аналары өлеше, процентларда | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 9.2. Гражданнар муниципаль хезмәткә кергәндә барлыкка килә торган коррупция барлыкка килү куркынычын бетерү максатында муниципаль хезмәт өлкәсендә законнар таләпләрен үтәүне тәэмин итү | Җирле үзидарә органнары | 2015 – 2022 еллар | Көнкүреш коррупциясен киметүгә юнәлтелгән чараларның бер елга планлаштырылган гомуми саннан үткәрелгән | | | | | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9.3. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар бакчаларына электрон чират нигезендә керү чиратын саклауны тәэмин итү. Чират буенча нигезсез күчү мөмкинлеген искәртү.<br>ТР Арча МР мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының “Электрон балалар бакчасы” автоматлаштырылган мәгълүмат системасында ай саен туплану процессына мониторинг үткәрү | Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” МУ | 2015 – 2022 еллар | өлеше, процентларда | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 9.4. Мәгариф һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә ришвәтчелек күренешләре турында гражданнар мөрәҗәгатьләренә мониторинг алып бару | Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” МУ, “Арча район үзәк хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтек саклау учреждениесе | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 9.5. Медицина, мәгариф оешмаларында медицина, мәгариф хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә коррупция күренешләре мәсьәләләре буенча социология сораштырулары үткәрү. Сораштыру нәтиҗәләрен Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру | Арча муниципаль районы башкарма комитеты, “Арча район үзәк хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтек саклау учреждениесе | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 9.6. Татарстан Республикасы Арча һәм Әтнә районнары хәрби комиссариатында коррупциягә каршы тору | Татарстан Республикасы Арча һәм Әтнә | 2015 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| комиссияләренең нәтиҗәле, шул исәптән аларның эшчәнлегенә җәмәгатьчелек вәкилләрен җәлеп итү юлы белән, эшләвен тәэмин итү, | районнары хәрби комиссариаты | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9.7. Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәмәгән һәр очракта законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын куллануны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | Җирле үзидарә органнары | 2016 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 9.8. Җирле үзидарә органнары алдына куелган бурычларны үтәү өчен булдырылган оешмаларда коррупциягә кисәтү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру | Җирле үзидарә органнары | 2016 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 9.9. Муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турында законнар таләпләрен үтәүне тәэмин итү | Җирле үзидарә органнары | 2016 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - | - | - |
| 9.10. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмауга һәм җайга салуга кагылышлы коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренең үтәлешенә, шул исәптән мондый затларны аларны үтәмәгән очракта җаваплылыкка тартуга контрольлек итүне гамәлгә ашыру | Җирле үзидарә органнары | 2018 – 2022 еллар | | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - |
| 9.11 Ведомство карамагындагы оешма җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмауга һәм җайга салуга кагылышлы устав һәм хезмәт килешүләре таләпләрен үтәүне | Җирле үзидарә органнары | 2018 – 2022 еллар | Ведомство буйсынуындагы оешмаларның гомуми саныннан үткәрелгән тикшерүләр саны | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| контрольдә тоту, аны булдырмау һәм/яки җайга салу буенча чаралар күрү, шул исәптән әлеге таләпләрне үтәмәгән очракта мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу таләпләре үтәлергә тиешле затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Арча муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән программа буенча барлыгы | | | | | | | 505,0 мең сум | | | | | | | | | | | | | |